Республика Татарстан
**СОВЕТ**
**ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 22 нче апреле № 6

«Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегендә гражданнардан сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» 2007 елның 30 июлендәге 11 номерлы Ләке авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы нигезендә Ләке авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2007 елның 27 июлендәге 10 номерлы Совет карары белән расланган Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегендә гражданнардан сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Гражданнардан сораштыру билгеләү турындагы карар Ләке авыл җирлеге советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнардан сораштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Сарман муниципаль берәмлегенең рәсми сайты файдаланылырга мөмкин.

Гражданнардан сораштыру билгеләү турындагы карарда түбәндәгеләр билгеләнә:

1) сораштыру уздыру датасы һәм сроклары;
2) сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауны (сорауларны) формулировкалау;
3) сораштыру үткәрү методикасы;
4) сораштыру кәгазенең (сораштыру исемлегенең) формасы;
5) сораштыруда катнашучы муниципаль район халкының минималь саны.
6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru адресы буенча Сарман муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан файдаланып гражданнардан сораштыру

үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.

2) 22 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге бюджеты - җирле үзидарә органнары яки муниципаль район халкы инициативасы белән сораштыру уздырганда».

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге
Совет Рәисе Л.И.Шәрипова